- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Чемодурово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты-2021 елның 26 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2021 елның 26 ноябре-12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының өченче этабын уздыру вакыты-2021 елның 26 ноябре-15.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын үткәрү урыны-Чемодурово авылы, Нагорная урамы, 3А йорт, Чемодурово авылы Мәдәният йорты залы ;
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2021 елның 16 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча бирергә: Чемодурово авылы, Центральная урамы, 4 А йорт, Молодежная урамы, 20А йорт.
- Чемодурово торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Чемодурово авылы халкына, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән халык җыеннары турында хәбәр итәргә.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Чемодурово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Чемодурово авылы территориясендә үлән чабу, чүп-чар җыю хезмәтләре;
- Чемодурово авылында юлларны кардан чистарту;
- Чемодурово авылындагы зиратларны коймау; - «Сабантуй», «Авыл көне», «9 май», «өлкәннәр көне», «Яңа ел»бәйрәмнәрен үткәрүгә сувенир продукция сатып алу;
- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү;
- трактор өчен асылмалы җиһазлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

Чемодурово авылы, Үзәк ур., 4А , Чемодурово авылы, Молодежная ур., 20А,

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайты Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Н.Б.Котельникова